ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА ӘЛЕМ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

423762, Яңа Әлем авылы, Г.Тукай урамы, 55 йорт.

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОВОАЛИМОВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

423762, село Новое Алимово, ул.Г.Тукая, дом 55.

Карар
04.06.2021г.

Постановление
№ 8

**Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Яңа Әлем авыл җирлеге башкарма комитетының аерым норматив хокукый актларына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 30 декабрендәге 509-ФЗ номерлы Федераль законы, Актаныш муниципаль районының Яңа Әлем авыл җирлеге Уставы нигезендә, Актаныш муниципаль районының Яңа Әлем авыл җирлеге башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Актаныш муниципаль районы Яңа Әлем авыл җирлеге башкарма комитетының

- Яңа Әлем авыл җирлеге Башкарма комитетының «Гаилә составы турында белешмә, йорт кенәгәсеннән өземтә, гражданның җир кишәрлегенә хокукы булуы турында хуҗалык кенәгәсеннән өземтә, шәхси ярдәмче хуҗалык булу турында белешмә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 12.02. 2013 №3 374 нче номерлы карарына;

- « Яңа Әлем авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан гражданнар һәм юридик затларның мөрәҗәгатьләрен карау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында», 12.02. 2013 № 3 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 бүлек регламентларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- «Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән электрон формада административ процедураларны үтәү үзенчәлекләре, шулай ук күпфункцияле үзәкләрдә административ процедураларны үтәү үзенчәлекләре. Бүлек гомуми билгеләре белән берләштерелгән мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләренә күрсәтелгән хезмәтләрне күрсәтү тәртибен үз эченә алган дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтүнең, шул исәптән дәүләт яисә муниципаль хезмәт нәтиҗәсенә карата да, күрсәтелгән хезмәтләрне күрсәтү вариантларын үз эченә алырга тиеш».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында « Яңа Әлем авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга.

3. Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплыгымда калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе Д.М.Әнвәрова